КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 4 июль г.Казань № 459

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 16 февраль, 59 нчы; 2006 ел, 7 июнь, 282 нче; 2008 ел, 5 декабрь, 858 нче; 2009 ел, 24 февраль, 98 нче; 2010 ел, 31 март, 205 нче; 2011 ел, 10 июнь, 470 нче; 2011 ел, 13 август, 673 нче; 2012 ел, 17 август, 716 нчы; 2013 ел, 7 март, 153 нче; 2013 ел, 25 ноябрь, 924 нче; 2014 ел, 7 июнь, 387 нче, 2015 ел, 27 ноябрь, 897 нче; 2016 ел, 8 апрель, 202 нче; 2016 ел, 3 август, 531 нче; 2016 ел, 24 ноябрь, 873 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты турында нигезләмәгә, 5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.5 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«5.5. Комитетны үзгәртеп төзегәндә архив документлары (идарә итү, финанс-хуҗалык, шәхси состав буенча документлар, саклау вакыты вакытлыча булган документлар) тәртипкә салынган хәлдә хокук варисына тапшырыла.

Комитетны бетергәндә Татарстан Республикасы Архив фонды документлары, шәхси состав буенча документлар, шулай ук вакытлыча саклау вакыты чыкмаган документлар тәртипкә салынган хәлдә Татарстан Республикасы Дәүләт архивына саклауга тапшырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин